Республика Татарстан

ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

“ 16 ” 01 2019г. — № 2

2019 елга Ютазы муниципаль районының
гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне
кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын
тәэмин итү һәм су объектларында кешеләр
иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар
планын раслау турында.

1998 елның 12 февралендәге «Гражданнар оборонасы турында»гы, 1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында»гы Федераль законнар таләпләре, һәм 2019 елга Татарстан Республикасының идарәсе органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль подсистемасын әзерләү буенча оештыру - методик күрсәтмәләр нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елга Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планын расларга.
2. 2019 елга идарә органнарын, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гражданнар оборонасы көчләренең Ютазы районы звеносының территориаль подсистемасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне расларга.
3. Ютазы муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре, хезмәтләре җитәкчеләренә, җирлек башлыкларына Планның һәм аларга кагылышлы оештыру-методик күрсәтмәләрнең үтәлешен оештырырга һәм финанс белән тәэмин итәргә кушарга .
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

**Р.М. Нуриев**

А.Н.Захаров
2-81-49